Хәерле кич хөрмәтле ата-аналар!

Сезнең гаиләдә бала үсеп килә. Әлбәттә, сез аның үсешен бик нык күзәтеп барасыз. Уңышларына сөенәсез. Уңышсызлыкларына борчыласыз. Сез үз балагызны сәламәт кенә түгел, акыллы да, сәләтле дә булып үсүен телисез. Ләкин һәрвакыт без теләгәнчә генә килеп чыкмый. Бер яктан бала безне уңышлары белән сөендерсә, икенче яктан ул төрле сюрпризлар да ясарга мөмкин. Бу баланың психологиясе белән бәйләнгән. 5 сыйныфта бала яшүсмер чорына аяк баскан иде. Бу чорда организм бик нык үзгәрешләр кичерә башлый. 6-7  сыйныфларда уку бу чорның нәкъ уртасына туры килә. Организмдагы, холыктагы үзгәрешләр балаларда тагын да ныграк сизелә башлый.

Иң беренче, бу тышкы кыяфәттәге үзгәрешләр. Алар ямьсезләнәләр. Куллары озыная, борыннары, авызлары зурая, кисәк кенә буйлары үсеп китә.

Икенчедән, аның җенси өлгереше. Кызлар 11 яшьтән 14 яшькә кадәр бу өлгерешне кичерә, ә малайларда ул 12-16 яшьләргә туры килә.  Бу вакытта кеше "котырган гормоннар корбаны"на әверелә, алар баланың нерв системасына нык тәэсир итә.  Балалар тиз кызып китүчән,агрессив,  кыргый һәм тыңламаска әйләнә. Кызларда бу үзгәрешләр малайларга караганда иртәрәк башлана. Класстагы кызлар һәм малайларны чагыштырсак, кызлар гәүдәгә дә зуррак, активрак та.

Врачлар фикеренчә, яңа туган кыз малайларга караганда 2-3 атнага үсеше буенча алдарак бара. Кыз балалар иртәрәк сөйләшә башлый, иртәрәк йөри башлый. Яшүсмер чорына кыз баланың җитлегүе малайларга караганда  2 елга  алдарак бара.

Кызлар малайларга караганда тыңлаучанрак булалар. Хатын-кыз әйләнә-тирә мөхиткә ирләргә караганда тизрәк ияләшә.

Кызлар эшкә тизрәк алыналар. Малайлар эшкә тотынганчы, кызлар инде эшләп арган була.

Шунлыктан класс җитәкчесенең, укытучыларның уң куллары булып күбрәк кызлар тора.

Кызлар музыкага сәләтлерәк, алар сирәк ялгыша.

Малайлар кызурак канлы. Алар ызгыш-талашта – алты, юл хәрәкәтендә дүрт тапкыр ешрак катнаша.

Малайлар иҗатка ныграк тартыла. Бу – уенчыклар уйлап табучылар фикере. Чөнки малайлар яңа уеннар уйлап табалар, ә кызлар таныш уеннарны гына уйный икән

Гадәттә, кызлар күбрәк сөйләшә, дибез, ә белгечләр киресен исбатлый. Малайлар кешене тыңлауга караганда, үзләре сөйләүне артыграк күрә.

Сулагайларның күбесе малайлар икән. Гомумән, аларның сул кулы кызларныкына караганда иркенрәк хәрәкәтләнә.

Кызларның уң күзе яхшырак күрә, уң колагы яхшырак ишетә.

Малайлар математикага сәләтле.

Кызлар майлы, малайлар күбрәк тозлы ашамлыклар ашарга ярата.

Әйе, балалар төрле.

Гаиләдә дә тәрбия бертөрле генә бармый бит. Гаилә тәрбиясенең берничә төрен аерып күрсәтергә була.

**Демократик тип** - гаиләнең девизы “Без бергә!” Кечкенә яшьләрдән бу гаиләдә балага олы кешегә караган кебек карыйлар. Баланың фикеренә колак салалар. Бу гаиләдә гаилә членнары арасында бер-берсенә ярдәм итү, җаваплылык, игелеклелек кебек сыйфатлар өстенлек итә. Мондый гаиләдә тәрбияләнгән балалар хезмәт сөючән, мөстәкыйль, үз-үзләренә ышанучан булып үсәләр. Үскәч, тормышта дөрес урын таба алалар.

**Авторитар стиль (диктат)** - девиз “Нәрсә кушылган шуны эшлә!” бу гаиләдә балалар каты кул астында. Аларның һәр адымнары, эшләре күзәтелеп тора. Кечкенә генә гаеп булганда да, тәрбиягә каеш җигелә. Җәза алмас өчен алар еш кына ялганлыйлар

Мондый балалар өйдә тәртипле булалар, ә читкә чыгып киткәч, иркенәеп калалар.

**Попустительский тип (равнодушие) Гипоопека –** девиз "Ничек яшисең килсә шулай яшә!"

Гаиләдә бернинди тәрбия юк. Әти-әни үз эше белән, бала үз эше белән шөгыльләнә. Я ата-ананың баланы тәрбияләйгә вакыты җитми, алар зур постларда эшлиләр. Я бу авыр гаилә, ата-ана эчкечелек белән шөгыльләнә. (**Золушка) -** бу гаиләдә балага бөтен эш өелгән. Я ул дәрес әзерли, я өй эшләре белән мәшгуль. Мондый бала үз-үзенә ышанмый, юаш булып үсә.

Бала әти-әнисе белән аз аралаша, күбрәк компьютер каршында утыра, хәтта дуслары белән дә ул Интернет челтәре аша гына сөйләшә. Ә ата-ананы исә, көн-төн эштә, кешедән калышмыйча баланы киендерү, ашату-эчертү дигән уй күбрәк борчый.

Мондый гаиләләрдә балалар агрессив, эгоист булып үсәләр. Үзләренә игътибар эзләп төрле компанияләргә эләгәләр.

**Гаилә кумиры. Гиперопека** — бөтен игътибар балада. Бала әти-әни өчен хәзинә, һәрвакыт аны кечкенә итеп кабул итәләр. Мөстәкыйльлек бирелми. Һәрбер прихоты үтәлә. Баланың талантлары зурайтылып күрсәтелә. Аның гына баласы яхшы укырга, тәртип бозмаска тиеш. Бала эгоист, иркә, капризный булып үсә.

Кайсы актив. Кайсы бик тә актив - Гиперактивный. (дәрестә мондый бала белән эш төрләрен гел алыштырып торырга кирәк) Кайсы бик оялчан. Көннәр буе авызыннан бер сүз дә ала алмаган балалар бар. (болар белән аерым эшләргә кирәк).

Чыгышымны йомгаклап шуны әйтергә телим:

1. Балагыз нинди булуына карамастан яратыгыз - талантсыз булса да, уңышларга ирешә алмаса да. Аның белән бергә булуыгызга куаныгыз, чөнки бала – иң зур шатлык. Ләкин аны иркәләп бозмагыз.

2. Балага күбрәк игътибар итегез. Аның белән аралашыгыз, кызыксыныгыз.

3. Җыелган ачуыгызны баладан алмагыз, картлык көнегезгә әче икмәк әзерләмәгез.Чөнки ни чәчсәң, шуны урырсың.

4. Класста үзара конфликтлар килеп чыкканда, бервакытта да мәктәпкә килеп конфликтны үзегез генә чишү юлын карамагыз.

5. Баланы укытуны мәктәпкә генә йөкләп калдырмагыз. Өйдә һәрвакыт аның белән шөгыльләнегез. Өстәмә рәвештә бала белән укыймыйсыз икән, баладан яхшы билгеләр көтмәгез.

6. Баланың ачыктан-ачык сорауларыннан качмагыз, әгәр ул сорауларга җавап бирмисез икән, ул аларны сезгә бирүдән туктый һәм кирәкле мәгълүмәтне каяндыр читтән эзли башлый.

7. Балагызга карата дустанә мөнәсәбәттә булыгыз, шул вакытта ул да сезнең дустыгызга әйләнер.